**Чын ир**

# Рифкат Хуҗин: «Милли хәрәкәттәге бәйрәмнәрне уздырудан куаныч вә шатлык алам»

Шәхеснең кем икәнен белер өчен, аның белән янәшә эшләү генә җитеп бетми әле. Чөнки хезмәт дәверендә генә барлык сыйфатларын белеп бетерү мөмкин түгел. Бигрәк тә сүз ир-ат турында барса. Шуңа да Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Туктаргали углы Рифкат Хуҗинны сүтеп карарга булдым. Аның белән булган әңгәмәне урнаштырабыз.

**- Рифкат абый! Ничә яшегездә авылдан шәһәргә күчтегез һәм эчке халәтегездә нинди кыенлыклар кичердегез?**

- 33 яшемдә шәһәргә күчтем. Авылда үсеп, авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым. Ун ел буена эшемне яратып башкардым. Авылдан чыгып китүе миңа бик авыр булды. Икенче кыенлык: гаиләмнән башка бер елга якын ялгыз торуым, чөнки квартира мәсьәләсен чишкәнче, зур кызыбызның уку елын бетерү нияте белән гаиләм авылда калды.

**- Сез бүгенге көндә тормышыгызны җайга салган кешеләр исемлегендә. Ирешелгәнегез белән үзегез канәгатьме?**

- Бүгенеге көндә мин тормышым белән, эшем белән канәгатьмен.

Әле эшләмәгән эшләр күп, яуламаган биеклекләр дә бар.

**- Авылда татар халык гореф-гадәтләре нигезендә өлгергән ир буларак, шәһәр мохите холкыгызга үзгәреш керттеме?**

- Авылда яшәгәндә мин кешеләрнең берничә буынын белә идем. Шуңа күрә аларның нигә сәләтле икәнен яхшы белә идем. Холыкларын белә идем. Шәһәрдә боларны белер өчен көч куярга кирәк. Кырыслыгым шуннан да килеп чыга торгандыр.

**- Авылдагы Рифкаттән шәһәрдәге Рифкат ни белән аерыла?**

- Авылдагы Рифкат - яшь, тәҗрибәсез егет. Үзе белән эшләүчеләр күбесе олы булганга, күбрәк аларның фикерен тыңлап эшләргә тырышты. Шәһәрдәге Рифкатькә күп вакытта үзенә карар кабул итәргә туры килә. Эшне ятлар белән алып барырга туры килә.

**- Яшәештә туганнар арасындагы туганлык хисен саклау ни дәрәҗәдә читен һәм бу авырлыкның тамырлары кая тоташа?**

- Бүгенге заманда адәмнәр максат итеп байлык җыюны беренче урынга куя. Шуның өстенә әти-әнидән аерым яши. Әти-әни туганлык хисләрен яңартып торучы бер генератор ул. Бу авырлыклар булмасын өчен ата-ана гаиләдә балалар белән тиешле тәрбия алып барырга тиеш. Туганлыкны саклауда Ислам динебез зур роль уйный. Авыз ачулар, Корбан ашлары, мәет ашларын бергәләп үткәрү туганлыкны ныгыта.

**- Ир-ат буларак, хатыныгызга сөйләмәгән серләр буламы?**

- Эштә булган авырлыкларны хатынга сөйләп борчырга кирәк, дип тапмыйм. Хатыннан качырган серләрем юк.

**- “Хатыныгызны бер сүз белән генә сүрәтләгез,” - дисәләр, нинди сүзне сайлап алыр идегез?**

- Кызларымның әнисен, тормыш юлында минем белән янәшә баручы, миңа һәрвакыт терәк булган кешене мин бер сүз белән генә сүрәтли алмыйм. Аның турында поэмалар язарга кирәк.

**- Рифкат әфәнде, әти буларак ике кыз тәрбияләүче ата Сез. Балаларыгызны тәрбияләгәндә үзегезгә генә хас ысуллар бармы?**

- Үземә генә хас булган ысуллар кулланам, дип әйтә алмыйм. Һәрбер ата-ана үз баласын яраткан кебек, мин дә аларны яратам. Мин аларга бөтен



мәхәббәтемне бирәм. Алар да миңа шулай җавап бирәләр. Киңәшәләр. Әниләренә сөйләмәгән серләрен дә миңа сөйлиләр. Мин аларның терәге, һәм шуны тоеп яшәү миңа көч бирә.

**- Соңгы елларда, җигелеп балалар фестивален оештырасыз. Бу зур мәшәкать ике ай дәвам итә. Аннары гына олуг тантана булып сәхнәгә чыга. Пәрдә ябылгач, күңел түрегезнениләр били?**

- Милли хәрәкәттәге бәйрәмнәрне уздырудан куаныч вә шатлык алам. Рухи һәм икътисади байлыгымны балаларга садака итеп бүләк итәм. Балалар - безнең милләтебезнең киләчәге.

Һәр тамашада, һәр аш табынында балалар утырырга тиеш. Алар - гореф-гадәтләребезне дәвам итүчеләр.

**- Артистларның иҗади сәләтләренә генә мөкиббәнме Сез, әллә кешелек сыйфатларына да игътибар итәсезме?**

- Артистларның иҗади сәләтләре белән беррәттән аларның кешелек сыйфатларына да игътибар итәм. Сәхнәдәге артист белән сәхнә артындагы артист тәңгәл булмаса, күңелем кайта. Ул артистның иҗади сәләте дә кызыктырмый мине.

**- Милли хәрәкәт әйдаманы буларак халыкка танылдыгыз. Башка җәмәгать оешмаларындагы вазыйфаларыгызны да санап узыгыз әле. Ялгышмасам, полиция органнары да Сезне үз иттеләр?**

- Русиянең эчке эшләр министрлыгының Самар өлкәсе буенча идарәсендә җәмәгатьчелек белән эш алып баручы Шура әгъзасы.

**- Рифкат әфәнде, татар халык мәкале: “Бүрене аяклары ашата”, ди. Җәмгыять эшләрендә кайнау төп эшегезгә зарар китермиме?**

- Җәмгыять эшләрендә кайнау төп эшемә зарар китерми, чөнки минем җитәкчеләрем, коллегаларым бу эшемне хуплыйлар.

Татар халкының мәкале бар: «Ир-ат кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз».

**- Буыннар чылбыры өзелмәсен өчен ниләр эшләргә кирәк?**

- Оныкларымны сөяргә, турыннарымны күрү бәхетенә ирешергә. Яшьләребезгә дөрес юл күрсәтергә. Үзебезнең гореф-гадәтләребезне, татар телебезне саклап калырга.

Татарлар - глобализацияне җиңәрлек милләт.

**Әңгәмәне<br>Наилә САБИРҖАНОВА<br>алып барды.**

# «Карга боткасы»н бәйрәм итү - рухыбызны үстерү, тәрбияләү чарасы

Матур йолалар, гореф-гадәтләр гасырлар буена татар халкының тормышын җайга салып, бизәп килгәннәр.

Алардагы тирән мәгънә һәм серлелек - ул искитәрлек күренеш. Бабаларыбыз һәрвакыт табигать кочагына сыенып, аның серләрен аңлап һәм аны хөрмәт итеп яшәгәннәр. Алар батырып эшли һәм күңелле ял да итә белгәннәр. Аларның бөтен бәйрәмнәре табигатьтәге үзгәрешләргә, аның чорлары алышынуга бәйләнгән. Мәсәлән, Нәүрүз, Сабан туе, Сөмбелә.

“Карга боткасы” бәйрәме - ул Нәүрузне, яисә яңа елны каршы алуга ишарә ясаган, ә каргалар килүе яз килү билгесе булып саналган. Озын кыштан арыган халык яз һәм җәй килүен һәрвакыт сагынып көткәннәр. Каргалар үз канатларында язны алып килә, дип аларны мул итеп сыйлаганнар.

Бу көнне бала-чага карга боткасы пешерү өчен, өйдән-өйгә кереп, урам буена ризык җыеп йөргәннәр. Кемнең нәрсәсе булса, шулардан аз-азлап өлеш чыгарганнар: ярма, он, май, йомырка, ит.

Табигатьнең иң матур җирендә зур казан асып, карга боткасы пешергәннәр һәм такмаклар әйтеп, күңел ачып бәйрәм иткәннәр. Нинди генә бәйрәм булмасын, халыкны берләштерү, дуслаштыру, туганлаштыру чарасы булган.

Советлар чорында бу борынгы бәйрәмебезне искелек калдыгы, дип тыеп килделәр. Халыкның күңелен ача,



рухын үстерә, якынлыкны-туганлыкны арттыра торган бәйрәмнәр мыскыллаңып югалганнар. Алар аракысыз да күңелләрне күтәрә торган булсалар, соңгарак кертелгән бәйрәмнәргә атеизм сәясәте, табыннарга аракы менеп утырды. Гасырлар буена сакланып килгән гадәтләр тыелган өчен без бүген гади генә “Карга боткасы” бәйрәме турында да берни белмибез.

Аллага шөкер, “Яктылык” мәктәбендә хәзер гореф-гадәтләребезне, милли мәдәниятыбызны пропагандалауга, үстерүгә зур әһәмият бирелә, бу юнәлештә системалы рәвештә эшләр алып барыла. Укучылар, укытучылар концерт программалары әзерләп, ата-аналарны да чакырып, бәйрәмнәрне бергә үткәрәләр. Бу эш елдан-ел матуррак, оешканрак төстә уза бара.

Ә менә быелгы “Карга боткасы” бәйрәме мәктәп тормышына тагын бер матур яңалык булып керде. Башка бәйрәмнәр мәктәп залында уздырыла торган булса, бу чара табигать кочагында, саф һавада, шәһәр читендәге паркта узды. Укучы балалар белән аларның ата-аналары төрле уеннар уйнадылар, ярышларда катнаштылар һәм призлар яуладылар.

Олы буын кешеләренең күңелендә “Карга боткасы” кебек бәйрәмнәр әле дә кадерләп саклана. Ачлык, юклык вакытында пешерелгән ботканың тәмен алар үз гомерләре буена истә тоталар. Шуңа да бу бәйрәм аларның күңеленә, йөрәгенә якын һәм кадерле.

Мәктәп балалары өчен бу бәйрәм, һичшиксез, көчле тәрбия чарасы. Саф һавада тәмле пылау ашау да алар күңелендә матур бер истәлек булып калачак.

Бу уңайдан тагын бер матур күренешне телгә аласы килә. Ул - татар җәмгыяте оештыра торган милли чараларда дин әһелләренең дә актив катнашуы. Бу аралашуда үгет-нәсыйхәт сүзләрен ишеткән балалар күңелендә Исламга карата хөрмәт әле тагын да артачак һәм Аллаһы Тәгаләгә якынаю көчәячәк.

Самар Диния нәзарәте рәисе Талип хәзрәт Яруллинның, өлкә татарларының милли-мәдәни мохтарияте рәисе Минәхмәт әфәнде Хәлиулловның, мәктәп мөдире Радик Газизовның да катнашуы бу матур чараның дәрәҗәсен тагын да үстерде.

«Карга боткасы» бәйрәме - ул кеше күңелендә мәрхәмәтлек, киләчәк көнгә ышаныч, табигатькә мәхәббәт тәрбияли. Бәйрәмдәге рәсми педагогиканың Ислам диненә тыныч һәм уңай карашы да матур күренеш.

Бу якынаю, берләшү көчәйсә, киләчәктә җәмгыятебез әле тагын да тәрбиялерәк, уңышлырак булыр, дигән ышаныч туа.

Әйтергә кирәк, бу бәйрәмне матур һәм күңелле итеп үткәрү өчен “Яктылык” мәктәбе укытучылары бик зур тырышлык күрсәттеләр.

Киләчәктә бу бәйрәм үсеш юлында булып, киң колач җәйсен һәм халыкны шатландыра, рухи тәрбия бирә торган тагын матур чарага әйләнсен иде.

**Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.**